ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18. 12. 2025 Олы Кайбыч ав. № 567

2026 елга Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары балаларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләр хакы нормативларын раслау турында

1. Расларга:

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар беләнбалаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең 2024 елга бәя нормативлары (1 нче кушымта);

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмә (2 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмаларын гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларына йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүне әлеге карарның 1 пунктында расланган бәя нормативлары нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны «Интерент» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф. Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «18» 12.
567 номерлы карарына
1 нче кушымта

2024 елга гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар ташу өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделенең атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елына сум | автотранспорт чарасының бер километр йөрү ставкасы, елына сум |
| КАВЗ | 1 177 194,49 | 28,27 |
| ПАЗ | 1 177 451,99 | 28,42 |
| ГАЗ «Газель» | 1 155 206,40 | 18,17 |
| УАЗ | 1 154 753,20 | 16,08 |
| FIAT | 1 158 244,90 | 13,29 |
| Peugeot Boxer | 1 163 580,30 | 12,88 |
| Ford Transit | 1 163 837,80 | 18,29 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 1 179 388,39 | 25,07 |

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «18» 12
567 номерлы карарына
2 нче кушымта

Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балалар ташу өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативларын исәпләү тәртибе турында
нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмаларына йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең хакын исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактта узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының расланган маршрут паспорты кысаларында башкарылган, автотранспорт чарасың хисап елында фактта узган юлы буларак кабул ителә.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1 i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m)$$

биредә:

$S_i$ - муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ -m моделле автотранспорт чараларының факттагы үткән юлы, километр;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе ставкасы, бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән ташуны оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына бәя нормативы ставкасы, сум;

$M_m$ - m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.